| | | |
|---|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 1 « 10 » 01 2019 ЕЛ.

**2019 елда Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы гомумбелем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру**

Балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау, Спас муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны баланслы тукландыру нормаларын үтәүне тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 10 сентябрендәге "2018 елга айлык акчалата түләүләр һәм түләүләрнең башка төрләре турында" 767 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1.Гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә:

1.1. СанПиН 2.4.5.2409-08 6.8 пункты нигезендә белем бирү учреждениеләре укучылары өчен укучыларның бер уку көненә бушлай туклануын оештыруга каралган 7 сум 40 тиен субсидиядән, мәктәп яны участогыннан алынган керем һәм ата-аналар түләвеннән торган суммада ике тапкыр кайнар аш (иртәнге һәм төшке аш) оештырырга кирәк. Озайтылган көн төркеменә йөрүче балалар өчен өстәмә полдник оештырылырга тиеш.

1.2. Составында 4 һәм аннан күбрәк балалар булган гаиләләрдән укучылар өчен шул исәптән бер уку көненә укучыларның әлеге категориядә бушлай туклануын оештыруга каралган 32 сум 40 тиен күләмендәге субсидиядән, мәктәп яны участогыннан алынган керемнәрнең 90 тиеннән ким булмаган өлешеннән (мәктәп яны участогы булган очракта) торган кимендә 37 сум 30 тиенлек кайнар аш белән тәэмин итүне оештырырга;

1.3. Укучыларга социаль ярдәм чараларын күрсәтү буенча составы учреждение директоры тарафыннан расланган комиссия төзү. Комиссия составына туклануны оештыру өчен җаваплы тәрбия эшләре буенча директор урынбасары, ата-аналар комитеты вәкилен кертергә. Комиссия әгъзаларының гомуми саны биш кешедән дә ким булмаска тиеш.

1.4. Ата-аналар комитетлары аша туклану өчен акча җыюны оештырырга.

1.5. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә туклануны төрләләндерү өчен буфет эшен оештырырга.
1.6. Өйдә белем алучылар өчен айга бер тапкыр, айдагы уку көннәрен исәпкә алып бер балага көненә 7 сум 40 тиен исәбеннән айның 20нче көненнән дә соңга калмыйча, азык-төлек җыелмасын бирергә кирәк.
2. Мәктәп ашханәсендә туклануны унике көнлек меню белән башкарырга.
3. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» муниципаль учреждениесенә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының ата-аналар комитетларыннан туклану өчен ата-аналар түләвен кабул итүне оештыру.
4. «Спас муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе тарафыннан 4 һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрдәге балаларны бушлай туклandыруны оештыру өчен акча табарга. (2 нче кушымта)
5. Куркынычсыз, сыйфатлы, рациональ, баланслы туклануны тәэмин итү, әзер ризыкларның сыйфатын, әзерләү технологияләренең үтәлешен, санитария – гигиена таләпләренең үтәлешен, балаларны ашатуны контрольдә тоту максатында Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә бракераж комиссиясен булдыру.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Спас муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Е. А. Афоньшинага йөкләргә.

Спас муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе В.А.Осокин

Спас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе Карарына
1нче Кушымта
№ 1 « 10. 01. 201_ел.

Спас муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләренең өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ укучыларын туклангыруны оештыру тәртибе турында нигезләмә

1. Әлеге нигезләмә 4 һәм аннан да күбрәк балалы өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ булган гаиләләрдән булган муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләренең 1-11нче сыйныф укучылары өчен кайнар тукланyны түләүсез оештыру рәвешендә социаль ярдәм чараларын күрсәтү тәртибен билгели. Әлеге категориядәге укучыларга кайнар аш бирү көненә 37 сум 30 тиеннән дә ким булмаган күләмдә иртәнге кайнар аш рәвешендә бирелә.
2. Укучыларны туклангыруны оештыру өчен:
2.1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларга социаль ярдәм күрсәтү буенча комиссияләр оештырыла (алга таба - комиссия), комиссия составы учреждение директоры тарафыннан раслана. Комиссия составына тәрбия эшләре буенча директор урынбасары, педагогны, укучыларны туклангыруны оештыру өчен җаваплы педагогны, укучыларның ата-аналарының җәмәгать берләшмәләре вәкилләрен кертергә тәкъдим ителә. Комиссия әгъзаларының гомуми саны биш кешедән дә ким булмаска тиеш.
Комиссия:
- сыйныф җитәкчеләреннән әлеге нигезләмәнең 1 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча социаль ярдәм чаралары бирү турында гаризалар кабул итә;
- елга ике тапкыр укучыларның исемлекләрен раслый: 10 гыйнвардан 15 гыйнварга кадәр һәм 30 августтан 2 сентябрьгә кадәр сыйныф җитәкчеләре:
2.2. сыйныф җитәкчеләре:
- ата-аналардан әлеге нигезләмәнең 1 нче кушымтасы нигезендә форма буенча социаль ярдәм чаралары бирү турында гаризалар кабул ителә;
- гариза алган көннән өч көн эчендә гаризаны Комиссия каравына җибәрә.
2.3. ата-аналар:
- әлеге нигезләмәнең 1 нче кушымтасы нигезендә сыйныф җитәкчеләренә социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында гаризалар җибәрә;
- кирәк булган очракта комиссия соравы буенча гаилә составы турында белешмә тапшыралар.
2.4. укучыларны туклангыруны оештыру өчен җаваплы педагог:
- укучыларның факттагы санын исәпкә алып бара.
3. Гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчесе түбәндәгеләр өчен җаваплы:
- гамәлдәге законнар нигезендә укучыларны төп туклыклы матдәләр буенча балансланган кайнар аш белән тәэмин итүне оештыру;

- Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор Идарәсе белән килештерелгән ассортимент исемлеге нигезендә буфет продукциясен сату;
- Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы мәгариф бүлегенә укучылар реестрын дөрес һәм вакытында тапшыру.

**Спас муниципаль районы**
**гомуми белем бирү учреждениеләренең**
**өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ укучыларын**
**туклландыруны оештыру тәртибе турында**
**нигезләмәгә**
**1нче Кушымта**

**(Форма)**

В комиссию по организации питания
__________________________________,
(Ф.И.О. заявителя)
проживающего(-ей) по
адресу: __________________________

____________________________________

**Заявление**

Прошу предоставить моему сыну (дочери,), _______________

______________________________________________________________________
_____,
(Ф.И.О.)
учащемуся(-щейся) _____ класса, бесплатное питание

Дополнительно сообщаю:
_______________________________________________

______________________________-
________________________________________________.

________________ ____________________
(дата) (подпись)

Спас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе Карарына
2нче Кушымта
№ 1 « 10 » 01 2018 ел.

2019 елның 09 гыйнварыннан түләүсез тукландыруны оештыру өчен Спас муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә 4 һәм аннан күбрәк балалы гаиләләрдә яшәүче укучылар саны турында мәгълүмат.

| **Мәгариф оешмасы исеме** | | **Укучыларның гомуми саны** | **4 һәм аннан күбрәк балалы гаиләдә яшәүче укучылар саны** |
|---|---|---|---|
| 1 | Антоновка урта мәктәбе | 73 | 10 |
| 2 | Иж-Борискинода «Антоновка урта мәктәбе» МББУ филиалы | 20 | 3 |
| 3 | Болгардагы 1нче урта мәктәп | 441 | 25 |
| 4 | Болгардагы 2нче урта мәктәп | 519 | 12 |
| 5 | Бураково урта мәктәбе | 67 | 8 |
| 6 | Иске Рәҗәп урта мәктәбе | 65 | 3 |
| 7 | Ким урта мәктәбе | 88 | 15 |
| 8 | Кузнечиха урта мәктәбе | 21 | 5 |
| 9 | Никольск урта мәктәбе | 87 | 18 |
| 10 | Ямбактыда «Никольск урта мәктәбе» МББУ филиалы | 17 | 5 |
| | Аграмакта «Никольск урта мәктәбе» МББУ филиалы | 16 | 3 |
| 11 | Өчкүл урта мәктәбе | 66 | 26 |
| 12 | Полянка урта мәктәбе | 66 | 16 |
| 13 | Танкеевкада «Полянка урта мәктәбе» МББУ филиалы | 24 | 4 |
| | **Барлыгы:** | 1570 | 153 |
| | Кирәкле сумма | | 803250 |